ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
(V чакырылыш)

V (5) чакырылышның I утырыш
КАРАРЫ

**№ 4** **Кәрәкәшле ав.** **19 сентябрь 2025 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы район Советына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы вәкилен сайлау турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 15 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 статьясындагы 3 пункты, «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 42 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы **карар кылды**:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының вәкилен сайлаулар буенча яшерен тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга.
2. Татарстан Республикасы Ютазы район Советына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы вәкиле итеп 6 нчы Кәрәкәшле сайлау округы буенча депутат Батыров Фәндәс Фәвәдис улын сайларга.
3. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы "Рәсми Татарстан" Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.
4. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы М. Н. Мусин